Иманга юл

# ЭЧКЕЧЕЛӘР ТӘҮБӘСЕ

Бер шәехтән риваять итәләр: “Ишеттем мин Әбүән-Нәсыр әс-Сәмәркаидидан, имам Заһид Әбү Габдулла үзенең укучылары белән үтеп барганда, мәҗлес корып хәмер эчеп утыручыларга туры килде. Имамның иптәшләре хәмер эчүчеләрне кыйнап-сугып, савытларын ватып бу эштән тыярга теләделәр. Хәзрәти Әбү Габдулла әйтте:

- Сез куегыз, мин аларны үзем тыйыйм әмер мәгъруф вә нәһи мөнкәр (шәригать кушкан эшне эшләп, тыйганыннан тыелырга боеру) юлы белән өйрәтим, - диде.

Бәс, эчкечеләргә якын килде. “Әссәламе галәйкем” дип сәлам бирде. “Үә галәйкем” дип сәлам алдылар. Арадан берсе торып бер кадәх (эчемлек эчә торган савыт, зур рюмка, бокал) хәмер тутырды. Шәехне бер кеше эчергә нәфесе белән килгәндер дип, шәехка сузды. Шәех кабул кылып алып кулына тотты. Вәәйтте:


- Әй егетләр, сезнең гадәтегездәндер ки, хәмер эчкән мәҗлестә төрле хәбәрләр сөйлисез. Мин дә сезләргә тиешле сүзләрне сөйләр идем, - диде.

Егетләр әйттеләр:

- Бик хуп, сөйлә.

Бәс, шәех әйтте:

- Әй кардәшләрем, без шул көнне искә төшерик ки, беркөн килеп ятар безнең тәннәребез кабергә, күтәрелеп илтенер җаннарыбыз күккә, күтәрелер йортларыбызда малларыбыз, мираслар бүленер.



Һәм шул көнне искә төшерик ки, анда безгә кычкырылыр, “Сез дөньяны җыйдыгызмы яки дөнья сезне җыйдымы? Дөньяны сез кабул кылдыгызмы яки дөнья сезне кабул кылдымы? Дөньяны сез куйдыгызмы яки дөнья сезне куйдымы?” - дип.

Һәм шул көнне хәтергә китерик ки: безне беркөнне җеназага куярлар. Ул вакытта безгә кычкырылыр:

- Кайда сезнең куәтле нәфесләрегез? Сезне кем зәгыйфьләндерде, көчсезләндерде? Кайда сезнең матур сөйли торган телегез? Сезне кем сөйләүдән туктатты? Кайда сезнең күп дусларыгыз? Сезне кем ятсындырды?

Һәм шуны искә төшерик ки, кемдер, зәгыйфьләр атлана торган атка атлана. Аны дүрт адәм күтәрә. Ул ат өстеннән без кычкырабыз:

- Әй туганнарым, әй кардәшләрем, әй минем җеназамны күтәрүчеләр! Сезне дөнья алдамасын, мине алдаган шикелле. Ул сезнең белән уйнамасын, минем белән уйнаган шикелле, - дип.

Һәм искә төшерик кабернең безгә әйткән сүзләрен. Ул әйтер: Мин караңгылык өемен. Ятсыну вә куркыныч өемен. Әллә син, минем өемнең куркынычлыгын караңгылыгын онытыңмы? - дип.

Һәм шул көнне искә төшерик ки, ул көндә кайбер йөзләр кара, кайбер йөзләр ак булыр. Без белмибез кайсы гөруһтан-төркемнән булачагыбызны.

Һәм шул көнне искә төшерик ки, аны Аллаһы Тәгалә әйтте: Кемнең гамәл дәфтәре уң кулына бирелсә - шатлык, кемнең гамәл дәфтәре сул кулына бирелсә, салыныр, дип. Без кайсыннан булачагыбыз мәгълүм түгел.

Һәм шул көнне искә төшерик ки, Аллаһы Тәгалә әйтте: Кыямәт көнендә гамәлләрне үлчи торган гадел үлчәү куярбыз.

Һәм шул көнне искә төшерик ки, Аллаһы Тәгалә хәбәр бирде: “Ќыямәттә бер гөруһ җәннәттә, бер гөруһ тәмугта булыр”, - дип.

Бәс, шәех хәзрәтләре сүзен бу урынга ирештергәч, хәмер мәҗлесендә булган барча егетләр урыннарыннан сикерешеп тордылар да, мәҗлесләрендә булган барча хәмер савытларын һәм азу коралларын ватып-сындырып аттылар. Аллаһы Тәгаләгә ихлас белән тәүбә кылдылар. Тәүбәләрен күркәм кылдылар. Ничек Аллаһы Тәгалә Каләме Шәрифендә (Коръәндә) әйтте: Аллаһы Тәгалә шундаен Тәңре ки, Ул бәндәләреннән тәүбәләрен, гөнаһка үкенүләрен кабул кыла һәм гөнаһларын ярлыкыйдыр.

**Кәнзил-хикәят китабыннан.**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рабиғүл ахыр-Йомадиәл әүүәл 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл.**

| Рабиғүл-ахыр Йомадиәл-әүүәл | Аҙна көндәре | Февраль, Март | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығы | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Шәмбе | 16 | 8.08 | 9.38 | 14.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 7 | Йәкшәмбе | 17 | 8.05 | 9.35 | 14.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 8 | Дүшәмбе | 18 | 8.03 | 9.33 | 14.30 | 17.57 | 19.27 | 20.57 |
| 9 | Шишәмбе | 19 | 8.01 | 9.31 | 14.30 | 17.59 | 19.29 | 20.59 |
| 10 | Шаршамбы | 20 | 7.59 | 9.29 | 14.30 | 18.01 | 19.31 | 21.01 |
| 11 | Кесе йома | 21 | 7.56 | 9.26 | 14.30 | 18.03 | 19.33 | 21.03 |
| 12 | Йома | 22 | 7.54 | 9.24 | 14.30 | 18.05 | 19.35 | 21.05 |
| 13 | Шәмбе | 23 | 7.52 | 9.22 | 14.30 | 18.08 | 19.38 | 21.08 |
| 14 | Йәкшәмбе | 24 | 7.49 | 9.19 | 14.30 | 18.10 | 19.40 | 21.10 |
| 15 | Дүшәмбе | 25 | 7.47 | 9.17 | 14.30 | 18.12 | 19.42 | 21.12 |
| 16 | Шишәмбе | 26 | 7.45 | 9.15 | 14.30 | 18.14 | 19.44 | 21.14 |
| 17 | Шаршамбы | 27 | 7.42 | 9.12 | 14.30 | 18.16 | 19.46 | 21.16 |
| 18 | Кесе йома | 28 | 7.40 | 9.10 | 14.30 | 18.18 | 19.48 | 21.18 |
| 19 | Йома | 1 | 7.37 | 9.07 | 14.30 | 18.20 | 19.50 | 21.20 |
| 20 | Шәмбе | 2 | 7.35 | 9.05 | 14.30 | 18.22 | 19.52 | 21.22 |
| 21 | Йәкшәмбе | 3 | 7.33 | 9.03 | 14.30 | 18.24 | 19.54 | 21.24 |
| 22 | Дүшәмбе | 4 | 7.30 | 9.00 | 14.30 | 18.26 | 19.56 | 21.26 |
| 23 | Шишәмбе | 5 | 7.28 | 8.58 | 14.30 | 18.28 | 19.58 | 21.28 |
| 24 | Шаршамбы | 6 | 7.25 | 8.55 | 14.30 | 18.30 | 20.00 | 21.30 |
| 25 | Кесе йома | 7 | 7.23 | 8.53 | 14.30 | 18.32 | 20.02 | 21.32 |
| 26 | Йома | 8 | 7.20 | 8.50 | 14.30 | 18.34 | 20.04 | 21.34 |
| 27 | Шәмбе | 9 | 7.18 | 8.48 | 14.30 | 18.36 | 20.06 | 21.36 |
| 28 | Йәкшәмбе | 10 | 7.15 | 8.45 | 14.30 | 18.38 | 20.08 | 21.38 |
| 29 | Дүшәмбе | 11 | 7.13 | 8.43 | 14.30 | 18.40 | 20.10 | 21.40 |
| 30 | Шишәмбе | 12 | 7.10 | 8.40 | 14.30 | 18.42 | 20.12 | 21.42 |
| 1 | Шаршамбы | 13 | 7.08 | 8.38 | 14.30 | 18.44 | 20.14 | 21.44 |
| 2 | Кесе йома | 14 | 7.05 | 8.35 | 14.30 | 18.46 | 20.16 | 21.46 |
| 3 | Йома | 15 | 7.03 | 8.33 | 14.30 | 18.48 | 20.18 | 21.48 |

# ВАҖИБ ГАМӘЛЛӘР

Әхмәд Хәди МАКСҮДИ

***Важиб гамәлләр дә фарыз кебек шәригатьтә кылырга боерылган гамәлдер. Важиб гамәлне кылган кеше саваплы булыр, гозерсез (сәбәпсез) кылмаган кеше гөнаһлы булыр, важиблыгына ышанмаган кеше, имансыз ук булмаса да, зур гонаһлы булыр. Мөэмин вә мөселман булган кешегә кылуы важиб булган гамәлләрнең мәшһүрләре 40тыр:***

1. Йорт кирәкләреннән артык малы булган кеше Рамазаннан соң фәкыйрьләргә үзе өчен вә сабый балалары өчен фитр сәдакасы бирү.

2. Йорт кирәгеннән артык малы булган кешегә Корбан гаете булган көннәрдә үзе өчен корбан чалу.

3. Ихрам кылып, Кәгъбәне тәваф кылып һәм Сафа илә Мәрвә таулары арасында йөреп, гомерендә бер мәртәбә гөмрә хаҗын кылу (гөмрә хаҗы фарыз булган хаҗдан башкадыр, кайсы айда кылынса да дөрес).

4. Гает фитр вә гает корбан намазлары уку.

5. Һәр көн ястү намазыннан соң витр намазын уку.

6. Зөлхиҗҗә аенда гарәфә гает вә тәшрикъ, гарәфә көннәрендә җәмәгать белән укылган фарыз намазларны укып, сәлам биргәч тә тәкбир тәшрикъ әйтү.

7. Коръәнне тәҗвид кагыйдәләренә муафыйк итеп, дөресләп уку.

8. Көръәндәге 14 сәҗдә аятьләреннән берсен укыган вә ишеткән кеше сәҗдәи тиләвәт кылу.

9. Вәгъдә вә гаһед (килешү) кылып әйтелгән эшне үтәү.

10. Аллаһы Тәгаләнең исемен тәгъзыйм белән олылап (Тәгалә. Тәкаддәсә, Вәҗәллә шаэ-нүһү) диеп зекер кылу.

11. Киләчәк заманда бер эш кылуны сөйләгән вакытта, иншә Аллаһ, кылырмын дию.

12. Хатын - иренә, ир - хатынына ягымлы булу.

13. Шәкерт остазын күреп, тәгъзыйм кылу.

14. Күңел илә һәр кешегә хәер эшләрне вә яхшылыкны теләү.

15 Көче җиткән кадәр адәмне вә хайваннарны һәлакәттән коткарырга тырышу.

16. Бирелгән бүләк вә һәдияне кабул итү.

17. Бүләккә каршы бүләк бирү.

18. Үзеңә яхшылык иткән кешегә яхшылык итү.

19. Хәләл тәгамле мәҗлескә чакырган кешенең мәҗлесенә бару.

20. Үзеңнең җәберең тигән кешедән гафу кылып бәхилләвен үтенү.

21. Алучыга сатлык малыңның гаепләрен сөйләү.

22. Иман әһеленең дөньяда рәхәтлеге вә ахирәттә изгелеге өчен кулыннан килгән кадәр хезмәт вә ярдәм кылу.

23. Иманлы кешенең эшен мөмкин кадәр яхшылыкка юрау.

24. Мөсафир кешегә өйлә, икенде вә ястү кеби намазларда дүрт рәкәгать фарызларны ике рәкәгать итеп кыскартып уку.

25. Бер мәҗлестә бер кешегә кылмаган гаепне кылды дип бөһтан (нахак) вә ифтира (яла ягу) кылынса, белгән кеше хаклык илә ул кешенең гаебе юклыгын сөйләп, аны яклау.

26. Ачу килгән кешегә, дин вә гыйбадәтенә зарар килмәслек булганда,өч көн тулгач, тышкы кыяфәттән булса да, үпкәне бетерү.

27. Муафыйк (лаеклы) кеше сораганда үзенең ризалыгы белән кыз баланы кияүгә бирү.

28. Ихрамлы кешегә кылу хәрам булган эшне кылган хаҗи тиешле корбан вә тиешле җәзасын үтәү.

29. Күркәм холыклар белән холыклану.

30. Һәрнәрсәгә гыйбрәт күзе белән карап, гыйбрәтләнеп, холыкны төзәтү.

31. Казый вә түрә булган кешегә мәзлумнарның шикаятен (гозерен) тыңлап, тугры хөкем кылу.

32. Галим булган кеше белер өчен соралган мәсьәләгә җавап бирү.

33. Казага калган намаз вә рузалары өчен үзе вафат булганчы варисларына фидия сәдакасы бирү илә васыять әйтү.

34. Үзе вафат булганчы калачак малдан вакытында бирелми калган зәкят-гошерләрен үтәү илә варисларына васыять әйтү.

35. Өстенә хаҗ фарыз булып та вакытында кыла алмаган кеше варисларына калган малдан бәдел хаҗы кылдыру илә үзе вафат булганчы васыять әйтү.

36. Варис булган кешеләр калган малның өч өлештән бер өлеше кадәресе белән мәетнең әйтеп калдырган васыятьләрен үтәү.

37. Ата-ана балаларына дин, гыйбадәт вә әдәпне өйрәтү.

38. Мөхтәрәм кардәш вә туганнар бер-берсенә дуслык кылышу.

39. Ике хатыны булган кеше хатыннарына тәрбиядә вә нәүбәтләрендә тигезлек вә гаделлек кылу.

40. Һәр гыйбадәттә важиб булган гамәлләрне үтәү. Мәсәлән: намазда 22 важиб, хаҗда 5 важиб, гөмрәдә 2 важиб бардыр.